| ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08 ноябрь, 2018 ел № 27/6

Шәһәр Советының 2016 елның 09 ноябрендәге «Җир салымы турында» 11/6 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсенә нигезләнеп,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2016 елның 09 ноябрендәге «Җир салымы турында»11/6 санлы Карарына (Шәһәр Советының 2016 елның 15 декабрендәге 13/7, 2017 елның 15 декабрендәге 21/7, 2018 елның 21 февралендәге 23/9 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2 пунктның 20 пунктчасын, 96-100 пунктчаларын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 3 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 7 пунктча белән тулыландырырга:

| | | |
|---|---|---|
| 7. | Россия Федерациясе Кораллы көчләре өчен хәрби-учет белгечлекләре буенча белгечләр әзерләү өчен автодромнар урнашкан җир участокларына карата | 0,03 |

3) 4 пунтның 6 пунктчасында «(парклар» сүзен «(шул исәптән, парклар, урамнар» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге Карарның 1 пункты 3 пунктчасы 2017 елның 01 гыйнварыннан соң барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләр өчен гамәлдә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев